Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлегенең
Мельничная авылында
ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«24» март, 2024 ел. №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 25 нче маддәсе нигезендә Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлегенең Мельничная торак пунктында халык җыены карар бирде:

1. 2023 елның 27 октяберендә Татарстан Республикасының Балтасинский муниципаль районының Чепья авыл җирлегенең Мельничная торак пунктында гражданнар җыелышы №2 карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 2 нче пункт түбәндәгечә расларга:

«2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту:

- Мельничная авылының Яшьләр урамы буенча юл-урам челтәрен һәм асфальт-бетон юлларны норматив хәлгә китерү;

беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:

- янгынга каршы гидрантка бер комплектлаучы әйбер сатып алу;".

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Чепья авыл җирлеге башлыгы А.Г. Нотфуллин